# IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ III СЕССИЯСЕ

## К А Р А Р №19

Мөслим «14» декабрь 2020 ел

**Мөслим муниципаль районының 2021 елга һәм 2022-2023 еллар план чорына бюджеты турында**

**1 Статья**

1. 2021 елга Мөслим муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Мөслим муниципаль районы бюджетының фаразланыла торган керем күләме 679 115,21 мең сум;

2) Мөслим муниципаль районы бюджетының гомуми чыгымнары күләме 679 115,21 мең сум;

3) 2021 елга Мөслим муниципаль районы бюджеты кытлыгы күләме 0,00 мең сум.

2. 2022 һәм 2023 елларга Мөслим муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) 2022 елга Мөслим муниципаль районы бюджетының фаразланучы гомуми керем күләме 678 742,01 мең сум, 2023 елга 683 075,66 мең сум;

2) Мөслим муниципаль районы бюджетының 2022 елга гомуми чыгымнар күләме 678 742,01 мең сум, 2023 елга 683 075,66 мең сум;

3) Мөслим муниципаль районының 2022 елга бюджет кытлыгы күләме 0,00 мең сум, 2023 елга 0,00 мең сум.

3. 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына Мөслим муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

**2 Статья**

1. 2022 елның 1 гыйнварына Мөслим муниципаль районының эчке бурычының югары чиген 0,00 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча бурычның югары чиген 0,00 мең сум күләмендә расларга.

2. 2023 елның 1 гыйнварына Мөслим муниципаль районының эчке бурычының югары чиген 0,00 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча бурычның югары чиген 0,00 мең сум күләмендә расларга.

3. 2024 елның 1 гыйнварына Мөслим муниципаль районының эчке бурычының югары чиген 0,00 мең сум расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча бурычның югары чиген 0,00 мең сум күләмендә расларга.

4. Мөслим муниципаль районы муниципаль бурычының иң югары чиге күләмен түбәндәгечә билгеләргә:

2021 елда – 0,00 мең сум;

2022 елда – 0,00 мең сум;

2023 елда – 0,00 мең сум.

**3 Статья**

Мөслим муниципаль районы бюджетында әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә 2021 елга һәм 2022, 2023 еллар план чорына фаразланган керем күләмен исәпкә алырга.

**4 Статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 60 статьясындагы 2 пункты нигезендә 2021 елга һәм 2022, 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары арасында керемнәрне бүлү нормативларын әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә расларга.

**5 Статья**

1. Мөслим муниципаль районы бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Муниципаль район бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының Баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

**6 Статья**

1. 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына Мөслим муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә расларга.

2. Муниципаль район бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләренең төркемнәре буенча 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына бүлүне әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә расларга.

3. 2021 елга гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 39 098,70 мең сум, 2022 елга 40 478,30 мең сум, 2023 елга 41 913,00 мең сум күләмендә расларга.

**7 Статья**

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрне:

2021 елга - 38 995,60 мең сум;

2022 елга - 38 174,00 мең сум;

2023 елга - 37 484,50 мең сум күләмендә, бүленеш белән, әлеге карарның 9 нчы кушымтасы нигезендә расларга.

**8 Статья**

Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны башкару вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күләмен:

2021 елга - 2 299,00 мең сум;

2022 елга - 2 323,40 мең сум;

2023 елга - 2 417,50 мең сум күләмендә, бүленеш белән, әлеге карарга 8 нче кушымта нигезендә расларга.

**Статья 9**

Мөслим муниципаль районы бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертларны:

2021 елга - 490 613,61 мең сум;

2022 елга - 480 161,31 мең сум;

2023 елга - 475 287,51 мең сум күләмендә, бүленеш белән, әлеге карарга 10 нчы кушымта нигезендә исәпкә алырга.

**10 Статья**

Мөслим муниципаль районы Юл фондының 2021 елга бюджет ассигнованиеләре күләмен 12 400,00 мең сум, 2022 елга 13 100,00 мең сум, 2023 елга 13 100,00 мең сум күләмендә расларга һәм аларны Мөслим муниципаль районының гомуми файдаланудагы юлларында 2021, 2022 һәм 2023 елларга юл эшләре программасы чараларын тормышка ашыруга юнәлдерергә.

**11 Статья**

1. Мөслим муниципаль районы җирле үзидарә органнары 2021 елда Мөслим муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең, шулай ук Мөслим муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм Мөслим муниципаль районы муниципаль учреждениеләренең хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

2. Җирле үзидарә органнарына 2021 елда муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарларны кабул итмәскә киңәш итәргә.

**12 Статья**

Мөслим муниципаль районы бюджетының 2021 елның 1 гыйнварына Мөслим муниципаль районы исеменнән төзелгән килешүләр нигезендә, 2020 елда муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле товарлар кайтарту, эшләр башкару, хезмәт күрсәтү өчен файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмаган күләме, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, 2021 елда күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

**13 Статья**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары Мөслим муниципаль районы бюджеты үтәлешен, шулай ук төзелгән килешүләр нигезендә Мөслим муниципаль районы бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыралар.

**14 Статья**

Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**15 Статья**

Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында https://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресы һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында http://muslumovo.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча урнаштырырга.

Мөслим муниципаль районы Башлыгы,
Мөслим муниципаль районы Советы рәисе Р.Х. Муллин